**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

"09" ноябрь 2021 ел Биклән авылы №5

**"Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында"**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы "Биклән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 ст. нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 19 нчы ноябре 13.00 сәгатькә билгеләргә.
2. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 20 нче ноябре 13.00 сәгатькә билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Биклән авыл җирлегенең Биклән авылы территориясендә 2022 елда балигъ булган, Биклән авыл җирлегенең Биклән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләргә:

- Биклән авылы эчендәге юлларны төзекләндерү;
- халыкның мәдәни ялын оештыру (халыкның үзешчән сәнгатьтә катнашуы өчен музыкаль аппаратура һәм сәхнә костюмнары сатып алу);
- Чкалов һәм Әхмәтшин урамнарын тоташтыручы, Чкалов ур., 63, Әхмәтшин ур., 82 йортлары янында җәяүлеләр күперен төзекләндерү;
- Биклән авылының «Хәтер бакчасы» паркын һәм «Сабантуй " паркын төзекләндерү (әйләнә-тирәсенә койма урнаштыру, алма үсентеләрен сатып алу һәм утырту).

**"ӘЙЕ"** **"ЮК"**

4. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Тукай районы Биклән авылы Чкалов урамы, 20А адресы буенча үткәрергә.

5. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Биклән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Тукай районы Биклән авылы Ахметшина урамы, 69А адресы буенча үткәрергә.

6. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

7. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

8. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш.Сәхбеев